# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 22 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Экология кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш); Ватаным Татарстан, 2011, 18 октябрь) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 1 өлешендәге алтмыш алтынчы абзацында ", дәүләт стандартлары" сүзен төшереп калдырырга;

2) 3 статьяның сигезенче абзацында "контрольнең" сүзен "күзәтчелекнең" сүзенә алмаштырырга;

3) 8 статьяның 1 өлешендә:

а) алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"хуҗалык һәм бүтән эшчәнлек башкарганда региональ дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыру, федераль дәүләт экология күзәтчелеге үтәргә тиешле объектларны кулланып башкарыла торган эшчәнлектән гайре;";

б) җиденче абзацта "дәүләт экология контролен" сүзләрен "региональ дәүләт экология күзәтчелеген" сүзләренә алмаштырырга;

в) тугызынчы абзацта "контроль" сүзен "күзәтчелек" сүзенә алмаштырырга;

г) унөченче абзацта "Татарстан Республикасы тарафыннан дәүләт экология контроле уздырыла торган" сүзләрен "региональ дәүләт экология күзәтчелеге башкарыла торган" сүзләренә алмаштырырга;

4) 9 статьяның 1 өлешендәге бишенче абзацында "һәм күзәтчелеген" сүзләрен төшереп калдырырга;

5) 15 статьяның 2 өлешендә "дәүләт стандартларын һәм башка" сүзләрен төшереп калдырырга;

6) 28 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"28 статья. **Әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә норматив документлар**

1. Әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә норматив документлар белән хуҗалык һәм башка эшчәнлекне башкарганда үтәлүе мәҗбүри булган түбәндәгеләр билгеләнә:

эшләргә, хезмәт күрсәтүләргә һәм контрольнең тиешле ысулларына карата әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге таләпләр;

әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый торган хуҗалык һәм башка эшчәнлекне чикләүләр һәм аның шартлары;

әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге эшчәнлекне оештыру һәм шундый эшчәнлеккә идарә итү тәртибе.

2. Әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә норматив документлар фәнни-техник казанышларны, халыкара кагыйдәләр һәм стандартлар таләпләрен исәпкә алып эшләнә.

3. Әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә норматив документлар федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә раслана.";

7) 29 статьяда:

а) исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "Хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең экологик сертификациясе";

б) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2. Экологик сертификация федераль законнар нигезендә башкарыла.";

8) 34 статьяның $4^1$ пунктында ", капиталь ремонт ясау" сүзләрен төшереп калдырырга;

9) VII бүлек исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"VII БҮЛЕК

**РЕГИОНАЛЬ ДӘҮЛӘТ ЭКОЛОГИЯ КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ. ҖИТЕШТЕРҮ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ ЭКОЛОГИЯ КОНТРОЛЕ**";

10) 44 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

11) 45 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"45 статья. **Региональ дәүләт экология күзәтчелеге**

Региональ дәүләт экология күзәтчелеге Татарстан Республикасының вәкаләтле башкарма хакимият органнары тарафыннан үз компетенцияләре чикләрендә Россия Федерациясе законнары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.";

12) 46 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"46 статья. **Дәүләт күзәтчелеге органнары вазыйфаи затларының хокуклары**

1. Дәүләт күзәтчелеге органнарының әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә дәүләт инспекторлары булган вазыйфаи затлары Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә түбәндәге хокукларга ия:

дәүләт хакимияте оранннарының, җирле үзидарә органнарының, юридик затларның, индивидуаль эшкуарларның һәм гражданнарның дәлилләнгән язма гарызнамәләре нигезендә тикшерү уздыру барышында кирәкле мәгълүмат һәм документлар соратып алырга;

хезмәт таныклыгын һәм дәүләт күзәтчелеге органы җитәкчесенең (җитәкчесе урынбасарының) тикшерү билгеләү турындагы боерыгын (күрсәтмәсен) күрсәткәннән соң юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар һәм гражданнар тарафыннан хуҗалык һәм бүтән эшчәнлек башкарганда кулланыла торган территорияләргә, биналарга, корылмаларга, төзелмәләргә, шул исәптән чистарту корылмаларына тоткарлыксыз керергә һәм аларны тикшерергә, башка зарарсызландыручы җайланмаларны, контроль чараларын, техника һәм транспорт чараларын, җайланмаларны һәм материалларны тикшерергә, шулай ук кирәкле тикшеренүләр, сынаулар, үлчәүләр, тикшеренүләр, экспертизалар һәм контроль буенча башка гамәлләр уздырырга;

юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга һәм гражданнарга мәҗбүри таләпләрне бозулар ачыкланганда аларны бетерү, мәҗбүри таләпләр турында, үсемлекләргә, хайваннарга, әйләнә-тирә мохиткә, дәүләт иминлегенә, физик һәм юридик затлар мөлкәтенә, дәүләт яисә муниципаль мөлкәткә зарарны булдырмый калуны, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килүне кисәтүне тәэмин итү гамәлләрен уздыру турында күрсәтмәләр бирергә;

мәҗбүри таләпләрне бозуларга бәйле рәвештә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә, әлеге административ хокук бозулар турындагы эшләрне карарга һәм мондый хокук бозуларны булдырмый калу чараларын күрергә;

вәкаләтле органнарга җинаятьләр билгеләре буенча җинаять эшләре кузгату турындагы мәсьәләләрне хәл итү өчен әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнарны бозуларга бәйле материаллар җибәрергә;

мәҗбүри таләпләрне бозулар аркасында әйләнә-тирә мохиткә һәм аның компонентларына китерелгән зарарны түләттерү турындагы дәгъваларны Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә белдерергә.

2. Дәүләт күзәтчелеге органнары эштә катнашуга суд тарафыннан җәлеп ителергә мөмкин йә мәҗбүри таләпләрне бозулар аркасында әйләнә-тирә мохиткә һәм аның компонентларына, дәүләт иминлегенә, физик һәм юридик затлар мөлкәтенә, дәүләт яисә муниципаль мөлкәткә китерелгән зыянны түләттерү турындагы дәгъва буенча бәяләмә бирү өчен үз инициативасы буенча эшкә керешергә хокуклы.

3. Әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге дәүләт инспекторлары Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт тарафыннан якланырга тиеш.";

13) 47 статьяда:

а) 2 өлештә "дәүләт экология контролен башкаручы тиешле башкарма хакимият органына" сүзләрен "дәүләт күзәтчелеге органына" сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 өлешне үз көчен югалткан дип танырга.

14) 95 статьяның 6 өлешендәге 1 пунктында ", шулай ук техник регламентлар таләпләренә туры килми торган агып төшүче суларны" сүзләрен төшереп калдырырга;

15) 97 статьяга түбәндәге эчтәлекле 3 өлеш өстәргә:

"3. Су объектлары акваторияләрендәге, яр буе полосасы участокларындагы (шул исәптән гидротехник объектларга килеп кушылу участокларындагы), үзән участокларындагы гидроэнергетик объектларның имин һәм һәлакәтләрсез эшләвен, аларны имин эксплуатацияләүне тәэмин итү өчен сулардан файдалануның һәм яр буе полосасы участокларыннан (шул исәптән гидротехник объектларга килеп кушылу участокларыннан) файдалануның махсус шартлары булган саклау зоналары билгеләнә. Әлеге объектлар өчен саклау зоналарын билгеләү тәртибе, сулардан файдалануның һәм яр буе полосасы участокларыннан (шул исәптән гидротехник объектларга килеп кушылу участокларыннан) файдалануның махсус шартлары аларның чикләрендә федераль законнар белән билгеләнә.";

16) 98 статьяның 13 өлешендәге 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2) зиратлар, үләт базлары, җитештерү һәм куллану калдыкларын, химик, шартлаткыч, токсикологик, агулаучы һәм агулы матдәләрне күмү урыннары, радиоактив калдыкларны күмү пунктлары урнаштыру;";

17) 103 статьяның 3 өлешендә "санитария-эпидемиология һәм экология нормативларына" сүзләрен "санитария-эпидемиология таләпләренә һәм экология нормативларына" сүзләренә алмаштырырга;

18) 106 статьяның 3 өлешендә "санитария-эпидемиология, экология нормативларына" сүзләрен "санитария-эпидемиология таләпләренә, экология нормативларына" сүзләренә алмаштырырга;

19) 120 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"120 статья. **Федераль дәүләт урман күзәтчелеге (урманнарны саклау)**

Федераль дәүләт урман күзәтчелеге (урманнарны саклау) федераль законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.";

20) 121 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"121 статья. **Муниципаль урман контроле**

Муниципаль берәмлек территориясендә җирле үзидарә органнары тарафыннан федераль законнар нигезендә муниципаль урман контроле гамәлгә ашырыла.";

21) 122 статьяның 1 өлешендә "саклауга, яңартуга һәм файдалануга дәүләт контроле" сүзләрен "саклау, торгызу һәм алардан файдалану өлкәсендә федераль дәүләт күзәтчелеге" сүзләренә алмаштырырга;

22) 123 статьяның 2 өлешендә "тикшереп тору" сүзләрен "аларга федераль дәүләт күзәтчелеге" сүзләренә алмаштырырга;

23) 124 статьяның икенче абзацында "аларның үтәлешен тикшереп тору" сүзләрен "аларның үтәлешенә федераль дәүләт күзәтчелеге" сүзләренә алмаштырырга;

24) 134 статьяның 2 өлешендәге икенче абзацында "лицензиядә күрсәтелгән" сүзләрен "рөхсәт ителгән" сүзләренә алмаштырырга;

25) $135^6$ статьяда:
а) исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"$135^6$ статья. **Федераль дәүләт аучылык күзәтчелеге";**
б) текстта "Дәүләт аучылык контроле һәм күзәтчелеге" сүзләрен "Федераль дәүләт аучылык күзәтчелеге" сүзләренә алмаштырырга;

26) $135^7$ статьяга "эшкуарлар тарафыннан" сүзләреннән соң ", вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә" сүзләрен өстәргә;

27) 141 статьяның тугызынчы абзацында "дәүләт тау күзәтчелеге һәм геологик контроль органнары" сүзләрен "дәүләт тау эшләре күзәтчелеге органы һәм җир асты байлыкларын геологик өйрәнүгә, алардан нәтиҗәле файдалануга һәм аларны саклауга дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыручы орган" сүзләренә алмаштырырга;

28) 144 статьяга:
а) исемендә "дәүләт идарәсе" сүзләрен "идарә" сүзенә алмаштырырга һәм "контроле" сүзе алдыннан "дәүләт" сүзен төшереп калдырырга;
б) 1 өлештә "контроле" сүзе алдыннан "дәүләт" сүзен төшереп калдырырга һәм "контроле" сүзен "контроль" сүзенә алмаштырырга ;

29) 145 статьяның 1 өлешендә "тиешле режимны үтәүдә дәүләт контроленең" сүзләрен "махсус сакланылучы табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә дәүләт күзәтчелегенең" сүзләренә алмаштырырга;

30) 166 статьяның 2 өлешендә "дәүләт стандартлары" сүзләрен "таләпләр" сүзенә алмаштырырга;

31) 167 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"167 статья. **Калдыклар белән эш итү өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге**

Калдыклар белән эш итү өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы һәм Татарстан Республикасының вәкаләтле башкарма хакимияте органы тәңгәл рәвештә федераль дәүләт экология күзәтчелеген һәм региональ дәүләт экология күзәтчелеген башкарганда аларның компетенцияләре нигезендә алар тарафыннан гамәлгә ашырыла.".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2012 елның 13 гыйнвары
№ 5-ТРЗ